| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**Приказ** **Боерык**

22.05.2019 г. Казань № 137-од

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 16 ноябрендәге 174-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 18 ноябрь, 906 нчы номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында типлаштырылган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә **б о е р а м**:

1. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 16 ноябрендәге 174-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктының дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җәмгыятьтә коррупцион тотышка түзеп тормаучанлыкны формалаштыру.»;

5.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Совет карары буенча, Совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр һәм бәяләмәләр бирү өчен, Совет утырышына башкарма органнар, коммерцияле булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.».

2. Хокукый эш буенча әйдәп баручы киңәшче Д. А. Даниловка әлеге боерыкны законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Рәис Ф.С.Батков